**Глава**
**Марсовского сельского**
**поселения Дрожжановского**
**муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Чүпрәле муниципаль районы**
**Марс авыл җирлеге**
**Башлыгы**

422472 с. Нижний Каракитан , ул. Ленина, 30 тел. (84375) 31-1-35, факс: (84375) 31-1-36,
e-mail: Mars.Drz@tatar.ru, ОГРН 1061672003898,ИНН1617003300,

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

с.Нижний Каракитан

18.11.2021 г. № 21

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Марс авыл
җирлегенең Югары Каракитә торак пунктында
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст. нигезендә, ст.35 «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Марс авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Марс авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә белән расланган,
Марс авыл җирлеге Советының 2019 елның 7 октябрендәге 49/1 номерлы карары (2019 елның 15 ноябрендәге 51/6 номерлы редакциясендә) белән расланган
КАРАР БИРӘМ:
1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Марс авыл җирлегенең Югары Каракитә торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 1 декабренә 09:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Түбән Каракитә авылы, Ленин урамы, 30 нче йорт, Түбән Каракитә авыл мәдәният йорты.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Югары Каракитә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча түбәндәге эшләр:
- Калинин, Ворошилов, Ленин, Югары Каракитә авылларында гамәлдәге юлларга вак таш салу ; ;
- Югары Каракитә авылында карт агачларны кисү

«ӘЙЕ» « КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 3 көн эчендә халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Марс авыл җирлеге башлыгы: Р. М. Җәмәлетдинов